РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«29» февраль 2024 ел. Олы Кайбыч ав. № 245

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Кайбыч муниципаль районының 08.11.2021елның 08 ноябрендәге 74 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» Кайбыч муниципаль районының 08.11.2021елның 08 ноябрендәге 74 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаны кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2024 е. «29» 02
245 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына өч ай рәттән көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча хәл ителгән муниципаль торак фондының торак урыннары булган күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре килүе.
2. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы.
3. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча тикшерелә торган зат идарәсендәге күпфатирлы йортта гомуми милекнең төзексезлеген бетерү эшләрен башкару өчен ремонт бригадаларын атнага биш тапкырдан артыграк чакырту.
4. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт урыннары милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы хисап чоры белән чагыштырганда 50 %тан күбрәккә арттыру турында мәгълүмат ачыклау.